**1 нче сыйныфта әдәби уку дәресенә технологик карта**

**Тема. [къ], [к] авазлары, К, к хәрефләре**

| | |
|---|---|
| **Дәреснең максаты** | [къ], [к] авазлары, К, к хәрефләре белән таныштыру;<br>— сүз модельләре нигезендә [къ], [к] авазларын дөрес әйтергә өйрәтү;<br>— басма текстны орфоэпик нормаларга туры китереп уку күнекмәләрен үстерү;<br>— туган якка карата кызыксыну хисләре уяту. |
| **Планлаштырылган нәтиҗәләр** | Укучылар [къ], [к] авазларын дөрес әйтергә, әлеге авазларга характеристика бирергә өйрәнәләр;<br>басма текстны дөрес итеп укуга ирешәләр;<br>үз туган ягың белән горурлану хисе кичерәләр. |
| **Дәреснең тибы** | Яңа белемнәрне ачу дәресе |
| **Ресурслар** | Мияссарова И. Х.,  Гарифуллина Ф. Ш., Шәмсетдинова Р. Р. Әлифба: татар телендә башлангыч гомуми белем бирү  мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2011. – 56 – 57 бит.<br>Мияссарова И. Х.,  Гарифуллина Ф. Ш., Шәмсетдинова Р. Р. Әлифба. Методик кулланма. – Казан: Мәгариф – Вакыт , 2011. – 38 – 40 бит.<br>Дәрескә презентация, рәсемле әлифба, кояш, болыт рәсемнәре. |

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | УУГ |
|---|---|---|---|
| **I. Мотивация.**<br>**Максат.** Укучылар белән дәрескә уңай атмосфера тудыру.<br><br>**Көтелгән нәтиҗә**. Дәрескә кызыксыну уяна. | Сыйныфта уңай атмосфера тудыра, шигырь укый:<br>*Елмаеп карагыз дөньяга,*<br>*Рәхәт бит яшәве, шулаймы?!*<br>*Елмаеп яшәсәң көн саен,*<br>*Укырга, уйларга бик җайлы.*<br><br>*Хәерле көн, укучылар! Бер-беребезгә карап елмаегыз әле, бүген дәресебездә кунаклар бар - аларга да елмаю бүләк итик.*<br><br>*Безгә уңышлы көн теләп кояшта елмаеп тора.* | Укучылар елмаялар | **Коммуникатив:** уку процессын оештыру; үз хисләреңне белдерү һәм бәяләү. |
| **II. Белемнәрне актуальләштерү.**<br>**Максат.** Сүзгә аваз анализы ясау күнекмәләрен ныгыту.<br><br>**Көтелгән нәтиҗә.** Табышмак җавабы булган сүзне авазлары ягыннан тикшерә белү. | Табышмак әйтә:<br>-Балалар,сез табышмак яратасызмы?<br>-Сез нинди табышмаклар беләсез?<br>Табышмак безне нәрсәгә өйрәтә?<br>*Мин сезгә хәзер табышмаклар әйтәм, ә сез җавабын табарга табарга тырышыгыз.*<br><br>**Үзе бер бөртек, эче мең бөртек .(*Кабак*)**<br>**Кат-кат яфраклы, яшел төстә, түтәлдә үсә.( Кәбестә)**<br><br>*Мин ни өчен бу ике сүзне алдым* | Тапкырлыкка,эзләнергә,<br><br>уйланырга.<br><br><br><br><br><u>Кабак,кәбестә</u> җавабын әйтәләр<br>Авазларга характеристика бирәләр. | **Танып белү:** эзләнү, уку өчен кирәкле мәгълүматларны табу; сүз модельләре төзү.<br><br>**Коммуникатив:** укытучы белән диалогка керү; коллектив фикер алышуда катнашу. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *икән?* | | |
| **III. Уку максатын кую.**<br>**Максат.** Аваз анализлауда кыенлык тудыру.<br><br>**Көтелгән нәтиҗә.** Дәреснең темасын, максатын билгели алу. | Игътибар итегез әле, Кәбестә сүзендә [к] авазын ничек әйтелә, кабак сүзендә ничек әйтелә? ([къ] һәм [к] авазлары чагыштырыла)<br>Димәк ,балалакр без бүген дәрестә нинди хәреф белән танышабыз инде?<br>-([къ] һәм [к] авазларын белдерүче К,к хәрефләре белән танышабыз.( ка)<br><br>*Тактага Кк хәрефен кую.* | Дәреснең темасын әйтәләр:<br>*[къ],к авазын, К, к хәрефләрен өйрәнербез, алар белән сүзләр укырбыз.* | **Регулятив:** уку материалында укытучы күрсәткән ориентирны аңлау.<br><br>**Танып белү:** сүз моделе төзү; анализ алымын куллану.<br><br>**Коммуникатив:** коллектив фикер алышуда катнашу; укытучы белән берлектә эшчәнлекне планлаштыру.<br><br>**Шәхси :** танып белү мөмкинлеген үстерү; уку эшчәнлеге мотивын ачыклау |
| **IV. Яңа белемнәр ачу.**<br>**Максат.** [къ], [к] авазлары, К, к хәрефләре белән танышу.<br><br>**Көтелгән нәтиҗә.** [къ], [к] авазларына характеристика бирә белү. | [къ] авазын ачыклау алгоритмын тәкъдим итә:<br>*Укучылар, барыбыз да бергә [къ] авазын әйтәбез.*<br><br>Сорау куя:<br>*[къ] – сузыкмы, тартыкмы?Ни өчен?*<br><br>*Ә хәзер колакларыгызны каплап әйтегез: [къ] – саңгыраумы, яңгыраумы?*<br><br>*Схемада бу аваз нинди шартлы билге белән белдерелер?*<br><br>Дәреслек белән эшләүне оештыра:<br>*Ә хәзер “Әлифба” китабын ачабыз, нинди рәсем күрәсез?*<br><br>*Бу сүзнең схемасы белән танышыйк әле.*<br><br>*Курай һәм иләк сүзләрендә икесендә дә к хәрефе бар, алар ике сүздә дә бер төрле* | Авазны хор белән әйтәләр.<br><br>Тартык аваз булуын, аны әйткәндә һава агымының тоткарлыкка очравын әйтәләр.<br><br>саңгырау тартык икәнен әйтәләр.<br><br>Шакмак белән белдерелүен әйтәләр.<br><br>Курай, иләк рәсеме икәнен әйтәләр.<br><br>Схеманы карыйлар.<br><br>Сүзләрне кабатлап әйтеп карыйлар, калын һәм нечкә әйтелүен | **Регулятив:** укытучы белән берлектә яңа материалны ачу.<br><br>**Танып белү:** сүз моделе төзү; анализ алымын куллану.<br><br>**Коммуникатив:** диалогта катнашу; иптәшеңне тыңлау.<br><br>**Шәхси:** уку материалына кызыксыну белдерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *укыламы?*<br><br>*Димәк, калын сузыклар янында [къ], нечкә сузыклар янында [к] булып укыла икән. Бу авазларның икесенә билге булып бер хәреф – Кк хәрефе йөри.*<br><br>Аваз белән хәреф бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?<br>(**Авазларны әйтәбез һәм ишетәбез, хәрефләрне язабыз һәм күрәбез)**<br><br>*Дәреслек белән эшләүне дәвам итәбез: кыяр һәм карлыган ,күке сүзләрен төркемнәрдә тикшерәбез.* | ачыклыйлар.<br><br>Гәүдәләренең озынлыгы 25–40 см, авырлыгы 70–150 г. . Күчмә кошлар, апрель ахыры — май башында киләләр.20 якын йомырка салалар.<br><br>Кагыйдәне бер-берсенә әйтәләр. | |
| **Физкультминут**<br>Сүздә калын къ  авазы ишетәсез икән, кул чабабыз, нечкә к авазы ишетсәгез аяк белән шакылдыйбыз **китап, кабак, кавын, көрәк, калак, көймә, курай, иләк, катык, күк.** | | | |
| **V.Ныгыту.**<br>**Максат.** Уку күнекмәләрен үстерү.<br><br>**Көтелгән нәтиҗә.** Яңа авазлар белән сүзләрне, басма текстны дөрес укый алу. | [к] авазын сүздә ишетүгә “Куян һәм бабай” **экият-уенын** тәкъдим итү.<br>Каюм бабайурманга барган. Ул анда куянны очраткан. Алар бик дуслашканнар. Куянның бер дә урманда каласы килмәгән, бабайга ияреп авылга кайткан. Җәй буе алар бакчада бик тырышып яшелчә үстергәннәр. Бу яшелчәләрнең һәркайсында [к] авазы булган. (төрле яшелчә рәсемнәре күрсәтелә, укучылар экран алдына чыгып тиешлесен сайлап күрсәтәләр)<br>- Көз җитүгә мул итеп уңыш җыйганнар, урманда яшәүче төрле җәнлек-җанварларны кунакка чакырганнар. Аларның һәркайсында [к] авазы булган. (төрле җәнлек рәсемнәре күрсәтелә, укучылар экран алдына чыгып тиешлесен сайлап күрсәтәләр)<br>- Ләкин кунакка буш кул белән барып булмый бит. Җәнлекләр дә күчтәнәч алып килгәннәр. Аларның да һәркайсында [к] авазы булган.<br>( төрле җиләк-җимеш рәсемнәре күрсәтелә, укучылар | рәтләрдә эш | **Танып белү:** дәреслектә ориентлашу; текст белән эшләү.<br><br>**Коммуникатив:** диалогта катнашу; коллектив фикер алышу.<br><br>**Шәхси :** яңа белемгә кызыксыну белдерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | экран алдына чыгып тиешлесен сайлап күрсәтәләр)<br><br><br><br>Дәреслек белән эшне оештыра:<br>*Ә хәзер, укучылар, дәреслектәге кушылмаларны хор белән укыйк әле.*<br><br>*Чылбыр рәвешендә к хәрефе кергән иҗекләрне укыйк.*<br>Ачык иҗек, ябык иҗекләрне билгеләү.<br>Аңлату ни өчен ачык иҗек, ни өчен ябык иҗек?<br>*Ә хәзер, укучылар, дәреслектә бирелгән таблицаны карыйбыз, андагы сүзләрне үзегез укып чыгыгыз әле.*<br>Кызыл шакмак нәрсәне аңлата?<br><br><br>*“Туган ягым ” дигән текстны җөмләләп укыйбыз.*<br><br><br><br><br><br>Укыган текст буенча сораулар бирә:<br><br>— *Тауларны нинди дип атый?*<br>— *Аланда нинди моң яңгырый?*<br>— *Ни өчен миңа кадерлеләрнең кадерлесе.ди?*<br>Миңа үзегезнең туган авылыгыз, шәһәрегез турында сөйләгез әле.<br><br><br>*“Кама ярында” исемле текстны укыйбыз.*<br><br>Сүзлек эше:<br>**Кама** – елга исеме, баш хәрефтән языла.<br><br>Әңгәмә оештыра:<br>— *Сез тагын нинди елгалар беләсез?* | <br><br><br><br><br><br>Кушылмаларны хор белән укыйлар.<br>Парлап бер-берсенә укыйлар.<br><br>Чиратлашып сүзләр укыйлар.<br><br><br><br><br><br>Кызыл шакмак предметны белдерүче сүзләрне аңлата.<br><br><br><br><br>Текстны укыйлар, җөмләнең баш хәрефтән башлануын, ахырында нокта куелуын искәртәләр.<br><br><br>Укытучы сорауларына җавап бирәләр:<br><br><br>Текстны укыйлар.<br><br><br><br><br>Балалардан җөмләләр.<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>Балаларның җавабы. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Өстәмә мәгълүмат бирә:<br>*Кама елгасы* - Ә Кама елгасы Татарстан территориясе буйлап 380 километр ага. <u>Аның борынгы исеме – Чулман.</u> Чулман ярларына зур шәһәрләр: Чаллы, Алабуга, Түбән Кама, Чистай урнашкан. | *Берничә баладан сорау.*<br><br>Әңгәмәдә катнашалар. | |
| **VI.Мөстәкыйль эш.**<br>**Максат.** Мөстәкыйль уку һәм фикер йөртү күнекмәләре булдыру. | Эшне оештыра:<br>*Ә хәзер, укучылар, дәреслектә бирелгән таблицаны карыйбыз, андагы сүзләрне үзегез укып чыгыгыз әле.* | Мөстәкыйль укыйлар. | **Танып белү:** текст белән эшләү; анализ-синтез алымын куллану.<br><br>**Коммуникатив:** коллектив фикер алышу. |
| **VII.Рефлексия.**<br>**Максат.** Дәрестәге эшчәнлеккә нәтиҗә ясау.<br><br>**Көтелгән нәтиҗә.** [гъ], [г] авазларының яңгырау тартык булуын әйтә алу, үз эшчәнлегеңә дөрес бәя бирә белү. | Дәрес эшчәнлеген гомумиләштерә, нәтиҗә ясый:<br>— *Без бүгенге дәрестә нәрсә өйрәндек?*<br>— *[къ], [к] авазлары нинди авазлар?*<br>— *Безнең сыйныфта К хәрефенә башланган исемнәр юкмы?*<br>— *К хәрефенә башланган фамилияле кешеләр бармы?*<br>Укытучы укучылар эшчәнлеген бәяли, кәефне ачыкларга тәкъдим итә:<br>*Укучылар, дәрес башында кәефләребез барыбызныкы да яхшы иде. Дәрес ахырында ул нинди калды икән?*<br>— *Дәрес сезгә ошадымы?*<br>— *Кем дә кем бүгенге дәрес материалын яхшы аңладым һәм аны башкаларга да аңлатып бирә алам дип уйлый, шулар елмайган кояш күтәрәләр.*<br>— *Кем материалны аңладым, ләкин башкаларга аңлатып бирергә кыенсынам ди, алар аз гына моңсу кояш күтәрәләр.*<br><br>*Дәрестә бик актив* | Сорауларга җавап бирәләр:<br>— *[къ], [к] авазларын, К, к хәрефләрен.*<br>— *саңгырау тартыклар.*<br><br>Үзбәя бирәләр: кояш,моңсу кояш күтәрәләр.<br><br>Кәефләрен ачыклыйлар, кояшка авыз ясыйлар. | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *катнаштыгыз, молодцы! Дәрес тәмам.* | | |


*Автор : Сабитова Альбина Ханифовна*

*Бакый Урманче исемендәге “Гимназия № 2”.*

*Түбән Кама шәһәре.*